Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



9

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ СЕНТЯБРЬ * 2024 * КАЗАН

Александр АЛЁШИН



Алмаз ХӘМЗИН

Бөркү һава. "Чаян" бүлмәсенә
Беркем керми дигән чагында,
Марсель Гали килеп кермәсенме,
Шигырь укып, мобильнигында...

Язган "куырып", бар-барчасын,
Нык "пешергән" әйтеп хатасын.
Үзен әллә Кояш сукканмы –
Шәп язучы, Аллам сакласын!

Марсель ГАЛИЕВ

КАЗАН ЭССЕСЕ

Эссе. Тәхетеннән торып, Кояш
Коя гына тәкатьсез нурлар;
Койрык кыскан хәлдә күләгәләр,
Эреп агар кебек таш юллар.

Ни гайбәтче чыпчыклар да хәтта
Тынган, күләгәгә күмелеп.
Казансуның балыклары үртәп
Алкаламый, судан үрелеп.

Бәйсез имиләре ташып чыккан,
Кәс-кәс атлый Казан кызлары,
Бөтен дәүләтенә чишенүдән
Тыеп тора соңгы кыллары.

Башны чага утлы-үткен нурлар,
Кызган ләүкә – Ирек мәйданы.
Миллек тоткан "көрәшчеләр" заты –
Әби-сәбикәйләр кайдале?

Шәһәр ялда.
Мондый эсселектән
Сыекланган чакта баш мие,
Истирахәт кылып кайту кирәк,
Чишмәләргә генә баш иеп.

Минем хыял – эсселектән качкан
Арктиканың карлы ярында.
Кара смокинг кигән пингвиннар
Вәкарь белән аның алдында,
Берсен-берсе бүлеп, әй сөйлиләр
Салкын бозлы сафлык турында.

Адәми зат болар каршысында,
Йомшак кына әйтсәк – ерунда.
Бездә шулай, иптәш пингвиннар,
Ерундалар – олы урында.

Эссе монда. Әлсерәгән Казан,
Кояш шиңеп, күккә ябышкан.
Бу эсселек – җәза. Ә сәбәбе –
Адәм кылган гөнаһ-ялгыштан.

Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле «Чаян»! Гаҗәеп хәл, ләкин кулга алынган һәрбер түрәнең күкрәге тулы орден-медальләр. Берсенең адвокаты хәтта аларны тартмага тутырып судка да алып килде. Янәсе, карагыз, мин яклаган кеше нинди атказанган шәхес! Ә ватан өчен намуслы хезмәт куючылар хәтта юбилей медале белән дә билгеләнми калалар...

Л. МАГИСОВА

КАЗАН

– Бездә орденнарны хезмәт куйган урында түгел, ә аларны өләшкән урында бирәләр шул, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

ШОМБАЙ

ГАМИЛ АФЗАЛЧА...

Шома Шомбай бигрәк һәвәс җыр язарга,
Сирәк инде андый талант дөньяларда,
Эт күрсә дә, бет күрсә дә, илһам килә
Пафос белән кәгазь битен сызгаларга.

Түзә кәгазь: "Кер юучы хатын җыры",
"Ит сатучы Шакир ага Сафин җыры",
"Теш врачы Гайфетдинов Сафа җыры",
"Алкоголик Шәмсетдинов Гата җыры".

Биниһая төрле юк-бар, төрле чүп-чар,
Шуны укып сине бүлер, сине тотар.
Читкә борылып исни-исни пышылдыйсың:
И Ходаем, газаплардан үзең коткар!

АЛМАЗ ХӘМЗИНЧӘ:

Ләкин безнең Шомбай ага башкачарак,
Дөньяны ул күрә-чага "Чаян"чарак.
Дөрес юлга бора, денгә кертә, җайлый,
Җырчылар да аннан өркеп кенә җырлый.

Тик бер нәрсәгә теле үтми берничек:
Әйткәнен "өстә" утыралар гел печеп.
Югыйсә бабабыз яхшылыкка өнди,
Түрәләр генә колагына һич элми.

Яза "Чаян" безнең ничекләр яшәүне,
Күрә Шомбай ат кебек кешнәп эшләүне.
Хыял, максатларны баш төеп әйтә журнал –
Кирәкмәс, ди, үкенеп, терсәк тешләүне...

Михаил ЛАРИЧЕВ



Сергей КОКАРЕВ



Яшәү күңеллерәк хәзер

Сез ничектер, белмим, ә менә мин үземне шулхәтле бәхетле итеп тоя башладым. Шундый рәхәт булып китте. Элек барысы да тыныч иде, йокларга гына ят... Ә хәзер алай түгел. Яңа технологияләр барлыкка килде, ясалма интеллект дигәннәре, төрле цифрлар – һәм яшәү күңелләнеп китте... Цифровизация ярдәмендә бөтен юк-барны учта яткан кебек күрергә була.

Менә, мәсәлән, кызым туу белән мин аны ниндидер сайтлар аша мәктәпкә яздырдым. Вакыты җиту белән беренче сыйныфка кердек, ә анда безне суд приставлары көтеп тора. Минем җиде яшьлек кызым дәүләткә җиде йөз җитмеш сигез мең сум тиеш икән – берьюлы алты шәһәрдә коммуналь хезмәт өчен түләмәгән, имеш... Соңыннан очына чыктык, әлбәттә. Кайсына шалтыраттык, кайсына барып кайтырга туры килде... Ничектер ерып чыктык инде...

Ә улымның "Услуги" сайтында теркәлүе булды, һәм көтмәгәндә – шалт! – ике айдан безгә полиция килеп җитте... Ул инде күптәннән... теге... начар өндәмәләр өчен хөкемгә тартылган булып чыкты. Тикшерә башладык... Утыртуын утыртмадылар, тик миңа улымны ул таптан арындыру өчен ел буе чабып йөрергә туры килде...

Ирем яңа эшкә урнашырга булды, хезмәт хакы да әйбәт, урнашуы бик вакытлы да... Тикшерә башлаганнар, ә ул алкоголик икән, Горбачёв заманыннан ук учётта тора, имеш. Менә сиңа мә! Ә үзе гомер буе ашказаныннан зарланып йөрде бит. Кыскасы, алмадылар аны ул эшкә. Ә мин тагын аның документларын рәткә кертер өчен йөгереп йөрдем.

Шунда кинәт башыма килде: ә минем үземнеке ничек икән? Кызык өчен бурычларны күрсәтә торган сайтка кереп карадым. Әттәгенәсе! Төрле банклар белән ундүрт килешенү һәм бер өем арбитраж эшләре. Биш ел буе төрле шәһәрләр буйлап йөрергә туры килде. Кайда сөйләшенеп, кайда тартеп... Юк, ни дисәң дә, яшәү күңеллерәк хәзер.

Барысы да ачык, нәрсәне генә ялгасаң да, барысы турында бөтен нәрсәне белергә мөмкин. Тагын шул ягы да бар: беркем бернәрсә өчен җавап бирми. Мин инде кайберәүләр турында шундый әйберләр белдем... Сез аларны беләсез... Әле күршем сөйләгән иде – аңа Марстанмы, Венераданмы шалтыратканнар. Акча сорап. Әле ярый бездә бөтен кешегә ярдәмгә килүче өлкәннәр бар. Безнең турыда бөтен җирдә белеп торалар. Әле менә күптән түгел генә билгеле булды, бөтен кешенең шәхси мәгълүматлары интернетка кереп киткән ди. Әйбәт, шулай бит? Менә шундый хәл булган, диләр... Яңа ел алдыннан бөтенесе дә Кыш бабайга хат язалар бит, беләсездер... Махсус сайт та ачканнар. Кыш бабай җәй көне дә эшли башлаган икән, турыдан-туры балаларга мөрәҗәгать итә: "Кадерле балалар, сезнең әти-әниләрегез һәрчак эштә, аларның вакытлары юк. Шуңа күрә миннән бүләк аласыгыз килсә, миңа аларның паспорт мәгълүматларын, СНИЛС, ИНН, карта номерларын җибәрегез. Никадәр күбрәк мәгълүмат җибәрсәгез, шулкадәр күбрәк бүләк алырсыз".

Әй, мин сезгә телефоннар турында сөйләргә оныткан-мын бит әле. Безнең өйдә алар дүртәү: иремдә, үземдә һәм улым белән кызымда. Гел шалтыратып торалар, кызыксыналар: кайчан акчаны кайтарабыз, кайчан аны ышанычлы счётка күчерергә җыенабыз... Дөрес, соңгы вакытта күбрәк Париж һәм Олимпиада турында. Уеннар тәмамланды инде, ә французлар бөтен кандалаларны агуламаганнар, бөтен күселәрнең дә башларына җитмәгәннәр әле... Әллә ниләр өчен акча җыялар. Иң мөһиме: һәркемгә шәхсән мөрәҗәгать итәләр... Рәхәт бит... Культуралы халык шул... һәм шулай язалар да: "Хөрмәтлебез Нурия Габделхаковна!" Озын сүзнең кыскасы шул: яшәү күңеллерәк хәзер, элеккечә түгел... Цифрлар ясалма интеллектларны уйлап чыгарган кешеләргә рәхмәт яусын. Ә ясалма – ул бит табигый түгел – беркайчан да шиңми.

Евгений БУГРОВ







Вячеслав ШИЛОВ





• • •

Улының мәктәптәге уку әсбапларын карап чыккач, наркотиклар тикшерү җитәкчесе үзенең хезмәткәрләрен Мәгариф министрлыгына җибәргән. Күрәсең, шиге төшкән...

• • •

Хатын-кызлар сәер зат. Әниләре белән яшәгән ирләр аларны кызыксындырмый, ә хатын һәм балалары белән яшәгәннәрне хуп күрәләр.

• • •

Метрода һәрвакыт кеше күп була. Берәүләр эшкә бара, икенчеләре эштән кайта. Алар кайчан эшли – аңлашылмый.

• • •

Шикле икътисадка безне мәктәптә үк өйрәттеләр. Болай итеп: "Берне язабыз, икесе хәтердә!"

• • •

– Хәзерге сәнгатьне мин бөтенләй аңламыйм.

– Җайлы гына бит ул. Һәр әсәрне янәшәсеннән әйләнеп узарга була икән, ул – скульптура. Ә стенага эленеп торганы – картина.

• • •

– Яңа директорың ничегрәк? Аның белән эшләргә буламы?

– Искиткеч яхшы кеше! Аның белән, гомумән, эшләмәскә була!

• • •

– Шеф, үземнең улыма аның исемен кушкач, сөенечтән хезмәт хакымны арттырды.

– Миңа да арттырды, ләкин мин улыма аның фамилиясен бирмәдем.

• • •

– Ни өчен хатыннар озаграк яши, ә пенсиягә иртәрәк чыгалар?

– Шул пенсиягә иртәрәк чыгу аркасында бит инде алар озаграк яшиләр дә!..

• • •

– Әйтегез әле, ничек итеп каршыгызда чын морж торганны беләсез?

– Җайлы гына. Чын моржлар шәрә килеш коеналар.

– Димәк, әгәр дә бәкедә берәрсе киенгән килеш коенса, ул чыннан да морж түгел?

– Юк. Ул балыкчы.

• • •

Әтисе улын тарихтан «ике»ле алган өчен ачулана:

– Тарихтан укыганда минем гел «биш»ле генә иде!

– Син укыганда тарих әле бик кыска иде бит!



ИР белән ХАТЫН



КАЙДА СЕЗ, КАДРЛАР?

Татарстан мәктәпләрендә 2,3 мең педагог җитми. Иң зур ихтыяҗ – башлангыч сыйныф укытучыларында. Мәктәп коридорларында математика, физика, химия, рус һәм чит тел белгечләрен дә очрату кыен. Кадрлар җитмәү бигрәк тә Казан, Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләрендә сизелә. Педагогларның уртача яше инде 48 тирәсе. Шул ук вакытта, укытучылар җитмәүгә карамастан, республикада урта белем бирү учреждениеләре төзү дәвам итә – яңа уку елыннан 8,5 мең укучыга каралган сигез мәктәп ачылды.

БЕРГӘЛӘШЕП

Чаллыда ике полицейский җинаять статьясы буенча эләккән. Хокук сакчылары наркотиклар белән бер хатынны тоткарлаганнар. Әмма моны беркетмә-мазардан башка гына хәл итәргә булганнар. Сөйләшенү буенча, ул әйтелгән сумманы күчерә, ә тегеләре исә хатын һәм наркотиклар турында онытталар. Шулай итеп, акча полицейскийларга күчерелә, тик шул вакытта көтмәгәндә аларның коллегалары килеп чыга. Хәзер хокук сакчылары һәм наркотик сатучы суд эскәмиясендә бергәләп утырачаклар.



ПРОПИСКА БИЗНЕСЫ

Биектау районының Коркачык бистәсендә яшәүче хатын кечкенә генә бизнес оештырырга булган. Фатирына 132 рәсми теркәлмәгән мигрантны пропискага кертеп, ханым 100 мең сумнан артык акча эшләгән. Кунакчыл хуҗабикәнең мондый эштә эләгүе беренче тапкыр түгел икән – моңа кадәр инде аны шул ук прописка өчен 109 мең сумлык штрафка тарткан булганнар. Бу юлы суд шома хатынга үзенең торак мәйданына якын туганнарыннан башка кемне дә булса пропискага кертүдән тыйган.

КӨТЕЛМӘГӘН СӘБӘПЛӘР

Татарстанда яшәүчеләр арасында эшкә соңга калуның иң таралган сәбәбе булып хәле начар булу санала. Аннан соң "йоклап калганмын" һәм "юлда бөкеләр" бара. Ләкин кайчагында хуҗаларга хезмәткәрләреннән көтелмәгән сәбәпләр дә ишетергә туры килгәли. Алар арасында мондыйлары да бар: "миннән башка да ерып чыгарлар әле", "кәеф булмады", "эшкә барасы кирәк иканен онытканмын", "метрода бөкеләр", "хезмәт хакым транспорт чыгымнарын да капламый" һ. б.



Сергей КОКАРЕВ



Александр БРЮХАНОВ

Әдәбият мәктәбе

"Гадилектә – бөеклек... Кем инде хәзер егермешәр исем кергән романны укып чыгарга тырышыр. Бер эше булмаганнар гына. Чөнки ул әсәрдәге хәлләр белән танышып, ачыклап чыгу өчен генә дә байтак вакыт кирәк...

Повестьларда да андагы тайпылышлар һәм табигать чуарлыкларын тасвирлау алымнарын ачыклап маташуны кемнәр генә башкарып чыга алыр икән... Шул теләсә кайсы биттән укый башлаучылар гына керешсә инде мондый гамәлгә...

Ә язучы кешегә шул... ел буе роман язар, бастырырлар да, берәү дә сатып алмас, менә шулай итеп ел үтәр, акчалар әрәм булыр...

Шуңа күрә кыска хикәяләр, көлкеле һәм төрткеле итеп язылганнары бигрәк тә кулай, андыйлары яшәү мәгънәсен бик уйландырмый да...

Афоризмнар гына язсаң бигрәк тә әйбәтрәк... Кыска һәм төгәл, артык та түгел, ким дә, истә дә яхшы кала... Әйбәт бит инде...

Ләкин иң көчлесе – сүз... Сүз, сезнең яшәүгә мөнәсәбәтегезне һәм тирә-юньгә карашыгызны белдертә..." – һәм ул, чиләктәге нинди төстә икәнлеге билгеле булмаган буяуга пумаласын батырып, бетон коймага алагаем хәрефләр белән әшәке сүз язып куйды...

– Хәзер күпләр уйланыр, ни өчен шулай һәм ник, – һәм ул горур атлап, үзенең юлы белән китеп барды...

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Хатыннар мәхәббәттән юләрләнгән акыллы ирләрне яраталар.

Сөйгәнеңне яратырга өйрәтү белән, ул башкаларны өйрәтергә китә.

Бер-берсе өчен яратылганнарны башкалар алып бетерә.


Килеп йөрүче сөяркә китеп баручысыннан әйбәтрәк.

Ташлаганга кадәр ул аны кулында күтәреп йөртте.


Хыянәтче хатыннарны яратам. Ә хыянәтне күралмыйм.

Әгәр хатын-кыз бик чибәр икән, аңа сокланыр өчен утны сүндерәсе килә.

(Хатын-кыз белгечләре мәҗлесендә язып алынды.)



Виктор БОГОРАД







Виталий ВЕСНИН

"ХОТТАБЫЧ ОЕШМАСЫ"

Сөләй, юкны-бушка аударып, нишләргә белмичә көне буе урамда селкенә. Менә инде ярты ел буе беркайда эшләми һәм ни эшләргә дә белми. Дөресрәге, хәзер инде ул Сөләй түгел, ә Сөләйман Садриевич. Аңа утыз яшь, шуңа карамастан, тормышында бернәрсә үзгәрми – һаман буйдак.

– Нәрсә булса да ашарга иде, – дип уйлады Сөләй, "Хоттабыч карт шаурмасы" дигән белдерүне күреп. – Иртәдән бирле берни капкан юк.

Сөләй менюга күз төшерде һәм "фасфуд" дигән гомерендә бер кабып карамаган ризыкка заказ бирде. Кабып карау белән тәлинкәдә ак чәч шәйләде. Башта гауга күтәрергә уйлаган иде дә, соңрак тынычланды. Аның башына башка уй килде: бәлки ул тылсымлы чәчтер? Һәм пышылдап кына:

– Чүлмәктән су күтәреп, Хоттабыч чыксын! – диде.

Чыннан да, ул әйткәнчә, чүлмәктән Хоттабыч башы күренде.

– Нәрсәгә чакырдың? – диде ул ачу белән. – Сора, нәрсә телисең?

– Ә син миңа бүген фатир ясап бирә аласыңмы, хәзер? – дип, каушавыннан мыгырдап куйды Сөләй. – Мин бер бүлмәдә акча түләп тора идем, акчам бетте дә мине куып чыгардылар…

– Трах-табидох, – дип пышылдады карт, – бир бу мескенгә торыр җир. Булды. Бар. Менә ачкыч. Адресын ал.

Сөләй йөгереп түгел, очып китте. Биш минуттан соң инде ул яңа фатирында иде. Ләкин ремонт ясалмаган. Тәрәзә төбендә документлары ята, анда аның бу фатир хуҗасы икәнлеге язылган.

Иртән Сөләй яңадан "Хоттабыч карт шаурмасы"на килде. Кичәге кебек им-том ясап, ул картны чыгарды. Сорый:

– Бабай, анда бит ремонт ясалмаган, ә мин каян акча табыйм?

Карт авыр сулап, сукранып куйды.

– И Аллам, нинди яшьләр болар? Банктан кредит ал, ремонт ясаучылар белән договор төзе, сиңа бер атна эчендә бөтенесен эшләп бирәләр. Бар. Комачаулап йөрмә. Менә сиңа банк адресы.

– Тукта, тукта, – дип кычкырды Сөләй, – мин әле машина да сорарга телим… Бабакай, әйтә алмассыңмы аны ничек юнәтергә?

– Мин бит сиңа әйттем инде, кредит ал машинага да!

Шулай диде дә чүлмәгенә кереп югалды. Шул ук көнне Сөләй барлык договорларның эшен бетереп, тынычлангандай булды. Ләкин тиздән яңа мәшәкатьләр туа башлады: кредитны каян кайтарырга һәм процентлар түләү мәсьәләсе?

Һәм Сөләй яңадан "Хоттабыч карт"ка китте. Бу юлы эшләр күпкә тизрәк төгәлләнде: карт аны көтеп торган шикелле кыяфәттә иде.

– Менә сиңа диплом, менә синең оешмаң адресы, менә сиңа эшеңә юллама, – дип, карт печәтен алып, документларга шапылдатып чыкты. – Хезмәт хакы анда әйбәт, барысына да җитәчәк. Җүләр сатмасаң, әлбәттә. Бар. Сау бул.

Карт югалды. Ә Сөләй печәттәге язуны укып калды. Анда: "Хоттабыч һәм дусларың финанс-кредит оешмасы" дип язылган иде.





• • •

Буратино Карло атакайдан сорый:
–Ә мине ләкләк китердеме?
– Юк, тукран!

• • •

«Кызыл Калфак» әкиятенең чит ил әсәре икәнен аңлау кыен түгел. Чөнки бездә сумсалар белән әби яныннан кайталар, ә аның янына бармыйлар.


• • •

Өч башлы елан Айболитка килеп зарлана:
– Доктор, нишләргә дә белмим, эчем катты!..
– Берни дә эшләп булмый, җанкисәгем. Өч тамак белән тыгынасың, ә чыгу юлы берәү генә!

• • •

Сумсалар нәрсә белән булгандыр, билгесез, әмма Кызыл Калфак Бүре белән сөйләшкән, һәм алар бер-берсен яхшы аңлаганнар.







Көлке терапиясе

Ләбиб ЛЕРОН

ИНСУЛИН

Артык борчылмаска кирәк булган да бит,
Терсәк якын – тешләп кенә булмый шул.
Катнашканда һәрбер уен-тамашада,
Кирәк булган юри генә уйныйсы.

Ә мин, җүләр, тиле, чынлап яшәдем шул –
Кирәкмәгән җиргә барып кысылдым.
Һәм нәтиҗә, нәләт, озак көттермәде:
Диабетикларга бик тиз кушылдым.

Диабетон, метформин һәм октолепин,
Глибенкламид, янә килеп – сиофор...
Хастаханә. Ак палата... һәм система! –
Бер чирлегә күпме дару сыядыр?!

Онглизаны, гликазидны... юк, юк,
әйтеп тормыйм,
Сезнең башны болай да бит ару катырам.
Кереп тормыйм бөер, бавыр темасына...
Ни бит... Зарсыз яшәү барыбер дә яхшырак!

Йөри алам, шөкер, көләм... Бик яхшы ич!
Димәк, яшим, сөям, димәк, мин сулыйм.
Дәшмәү – алтын.
Хәзер бер дә кызмыйм... түзәм...
...Кызып китәр идем, кушмый иптәш инсулин!

• • •

Шәфкать туташы:

– Бер дә каушамагыз, аппендиксны кисү – иң гади операцияләрнең берсе.

Авыру, коты алынып, сикереп тора һәм ишеккә таба йөгерә. Аны бер табиб туктата:

– Нигә шулай курыктыгыз? Шәфкать туташы дөрес әйтте, бу чыннан да бик гади операция!

– Ләкин бит ул бу сүзләрне миңа түгел, хирургка әйтте!

• • •

Бәяләр бәйдән тәмам ычкынып, ялгыз пенсионерлар шешә җыеп йөргән көннәрнең берсендә авыру карчык табибка килгән. Тегесе сораша-сораша аны бик озак караган, аннары киңәшләр бирә башлаган:

– Сезгә, әби, йомырка, симез ит, майлы шулпа ашарга ярамый...

– И улым, – дип бүлдергән авыру, – шуларның берсе генә булса да, монда килеп йөрмәс идем!..

Анастасия ВАСИЛЬЕВА

Валерий ТАРАСЕНКО

ТИШЕК КӨПЧӘК

ЮЛ МӨГЪҖИЗАЛАРЫ

Законнар аларны бозар өчен яратылган, дип саный торгандыр кагыйдәләргә буйсынмыйча юлларда куып йөрүчеләр. Автомобиль инспекциясе чаң кага: республикада җилкуарлар саны артканнан-арта бара – юлларда алны-артны белмичә элдертү күпләр өчен гадәти рәвешкә әверелде. Кагыйдә бозу өчен штрафы да озак көттерми. "Узышчылар"-га хәвефле йөртү өчен "бәхет хатлары" даими рәвештә килеп тора, ә түләргә алар ашыкмый. Түләмәүчеләр арасында бай кешеләр дә, җитәкчеләр дә җитәрлек. Инспекторларның "кара исемлекләрендә" 402 йөзләгән түләнмәгән штрафы булган автоһәвәскәр исәпләнә. Андыйлар Казанда – 222, ә Чаллыда 41 кагыйдә бозучы.

Хокук сакчылары, кемнең кем булуына карамастан, һәр тәртипсез йөртүчене җавапка тартырга вәгъдә бирәләр. Барча "рекорд ияләре" белән яшәү урыны буенча җитди әңгәмәләр үткәреләчәк. Ә өстәмә чара сыйфатында юл тынычлыгын бозучыларның исемнәре киң җәмәгатькә җиткереләчәк. Безгә исә күреләчәк чараларның нәтиҗәсен генә көтәсе кала...

Людмила НИКОЛАЕВА



• • •

Юл инспекторы бер машинаны туктата:
– Иптәш шофёр, сез исерек бит!
– Сез, нәрсә, бер тамчы да капмадым.
– Йөгез, сулап карагыз әле! – һәм көпшәчеген суза.
Шофёр өреп ала, көпшә берни дә күрсәтми.
– И шайтан, ватылды микәнни? – Инспектор үзе өреп карый. – Юк, эшли!





АК ХАЛАТЛЫ ВАХТОВИКЛАР

Бүгенге көндә илдә 25 мең табиб һәм 50 мең урта дәрәҗәдәге медперсонал җитми. Хөкүмәт бу хәлдән чыгу юлын эзли һәм, күрәсең, аны тапкан. Ротация ысулы ярдәмендә медицина персоналының кытлыгын җиңәргә тәкъдим ителә. Ләкин табиблар үзләре смена эшчеләре булырга ашыкмыйлар, мондый эш өчен хезмәт хакы тиешенчә булырга тиеш дип саныйлар – аена ким дигәндә 200 мең сум. Дәүләт андый суммаларны бирә алмый, бу акчаны медицина персоналының килүенә шат булган эре шәһәрләрдәге шәхси медицина үзәкләре түли.

УТЛЫ ХЫЯЛ

Оренбургның Шарлык авылыннан 18 яшьлек егет коткаручы булырга бик хыялланган. Ул укырга керү һәм чыгарылышны көтмичә, шундук үзе өчен практика оештырган. Егет авылдашларының абзарларына һәм гаражларына ут төрткән, аннары Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләренең эшләрен кызыксынып карап торган. Булган вакыйгаларны егет телефонына төшергән, һәр детальне җентекләп өйрәнгән. «Практик күнегүләр»гә мондый ашкыну пироманга каршы ике җинаять эше кузгатуга китергән.

ӨСТӘМӘ ФУНКЦИЯЛӘР БЕЛӘН


Авыл җирлекләрендәге почтальоннарга персоналны саклап калу һәм аз хезмәт хакларын күтәрү өчен, берничә функцияне берләштерергә тәкъдим итмәкчеләр. Авыл «Печкиннары», мәсәлән, фельдшер булырга мөмкин – кан басымын үлчәргә, алдан диагноз куярга, укол ясарга мөмкиннәр. Алар шулай ук теләүчеләрне китапханәләрдән китаплар белән тәэмин итәргә яки даруханәләр һәм кибетләр өчен курьер булырга чакыралар. Ә өстәмә хезмәт хакын күтәрү мөмкинлеге каралмаган.

БЕР ТЕЛДӘ

Псков өлкәсендә ясалма интеллект бюрократик телне кеше теленә тәрҗемә итә башлаячак. Төзүчеләр әйтүенчә, бюрократик тел махсус конструкцияләр белән тулган, моны гади кешегә аңлавы авыр, ләкин аларсыз түрәләр халык белән аралаша алмый. Шуңа күрә, рәсми сөйләмне дөрес аңлату өчен, яңа технологияләр ярдәмгә килергә тиеш. Бәлки, алар хакимияткә һәм халыкка уртак тел табарга булышырлар?



Валерий ТАРАСЕНКО



Владимир СОЛДАТОВ

Дамир МОРТАЗИН

ИХ, БЕЛГӘН БУЛСАМ...

Фирма директоры Рафинадов кабинетында эш кәгазьләренә кул куеп утыра иде. "Керемнәр азая, отчетлар күбәя!" – дип, эче пошып уйга батты. Кинәт шалтыраган кесә телефондагы таныш булмаган номер аның күңелсез уйларын бозды. "Тагын мошенникларыдыр инде!" дигән сискәнү барлыкка килде күңеленә. Шулай да телефонның аргы башында кем икәнен беләсе килү эндәшергә мәҗбүр итте. Ләкин: "Сезне банкның куркынычсызлык хезмәте борчый" дигән гадәти сүзләргә:

– Әлү, Рафис, бу мин – Харис! – дигән тавыш ишетелде.

– Нинди Харис? – дип гаҗәпкә калды Рафинадов.

– Беләсең инде! Директор булгач, классташларыңны оныттыңмы! Харис Нафигуллин!

– Колобокмы? – Рафинадов моның мәктәп елларындагы кушаматын әйтеп куйды. Туп шикелле йомры иде шул ул.

– Мин, мин! Кем булсын инде! – дип шатланган тавышы яңгырап алды трубкада тегенең.

– Син бу елларда кайда югалып тордың? Беркайчан да классташлар белән очрашуларга килмәдең...

– Их, Рафис! – дигән ухылдау эленеп торды мобильникта. – Кайда гына булмадым, дөнья мине кайларга гына ташламады... Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт, барысы да хәзер артта калды. Хәзер минем гаиләм бар, йортым, машинам... Башкаларныкы сыман! Ә мин сине зур кеше булган дип ишеттем, директорлыкка үрмәләгәнсең...

– Әллә ни зур түгел инде, – дип тыйнакланды Рафинадов. – Боргаланам, сыргаланам шунда... Ә син мине ни өчен искә төшердең? Ностальгия, әллә картаясыңмы, әллә нинди дә булса йомышың бармы?

– Алай хыялга бирелгән юк, картаерга ашыкмыйм, ә шалтыратуымның сәбәбе – сине кызымның туена чакырасым килә.

– Кызыңның туена? – дип гаҗәпкә калды Рафинадов. – Рәхмәт, әлбәттә. Нинди хөрмәттән? Мин бит синең белән бик үк тыгыз дуслар түгел дә идек бугай, синең гаиләң белән дә таныш түгел. Ә син мине көтмәгәндә туйга ук чакырасың!

– Беләсеңме, Рафис... Ничегрәк аңлатыйм икән? Син – директор!

– Шуннан ни булган?

– Ә кияүнең почётлы кунагы да директор була. Дипломатлар әйтмешли, тигезлекне сакларга кирәк, русча әйтмешли – равенство представительства соблюсти. Проще говоря, не упасть в грязь лицом.. Аларныкы директор, ә без алардан ни белән ким!

– Ни өчен нәкъ менә мин кирәк?

– Бүтән чара юк! Мин инде бөтен туганнарны йөреп чыктым – якыннарын да, еракларын да, танышларны да – күренеклеләре юк. Юк бездә директорлар, хет үзең тудыр! Әйдә, коткар классташыңны. Бул шундый... туй директоры! – дип күтәренке рухта әйтеп бетерде үзенең фразасын Рафинадов.

– Менә шундыйрак! Бу тантана икенче атнада, унбишендә...

Рафинадов уйланып торды да алдады.

– Бик шатланып булыр идем дә, ләкин бит мин ул көнне командировкага китәм.

– Их, кызганыч! – дип борчылу белдерде Нафигуллин. – Нишләргә соң? Бәлки, берәрсен тәкъдим итәрсең? – дип ялварып сорады яңадан.

– Моны эшләп була! – диде дә Рафинадов, – безнең мәктәпнең директоры Вәли Вәлиевичны чакыр! – дип йомгаклап куйды.

– Аны чакыра алмыйм шул. Сигезенче класста укыганда «ике»ле куйган өчен мин аның машинасының тәгәрмәчен тишкән идем. Ул чагында әле мине балалар бүлмәсенә милициягә йөрткәннәр иде. Вәли Вәлиевичнең исендәдер әле бу... Их, белгән булсам ул чакта хәзер аның кирәген, машинасына тию түгел, юып куяр идем.

Телефонда кызганыч ахылдау тавышлары гына ишетелеп калды.

Максим СМАГИН

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

«Ура, каникулллар!» дип кычкырганда, укытучылар укучыларга караганда ныграк шатланалар.

Өй эшләре балалар белән ата-аналарның мөнәсәбәтләре бозылыр өчен генә кирәк.

Элек бердәнбер репетитор – эти каешы гына иде.

Баланың мәктәптә беренче өч ел укуы – ата-аналар өчен рәсем ясау, пластилиннан әвәләү, төсле кәгазьләр ябыштыру – мавыктыргыч бәйге ул.

Игорь КИЙКО

Радиф СӘГЪДИ

НУ, ВАСИЛИЙ АГАЙ!..

Рәсәйнең атказанган артисткасы Исламия Мәхмүтованың әтисе яшь чагында бик үткен, җор телле җегет була. Бәйрәм көннәре җитсә, бер-ике иптәшен ияртеп күрше чуаш авылына барып кан кыздырып кайта торган гадәткә өйрәнеп китәләр. Килеп керәләр дә икән таныш кешеләренә: "Ну, Василий агай, синең кебек юмарт адәмнәр юк бугай бу дөньяда, менә сезгә кайчан гына килеп кермә, самогоныңны да чыгарып куясың, закускаңны да кызганмыйсың, юк ул безнең татарда синдәгедәйләр", – дип мактагач, чуаш агае чоланнан зур бер бутыл алып кереп җегетләрне сыйлый икән.

Икенче бәйрәмдә дә Чаллы егетләре чуаш авылына сузылган сукмакны суытмыйлар. Килеп керәләр дә икән: "Ну, Василий агай, менә син, ичмасам, самогоныңны да кызганмыйсың, закускаңны да мулдан куясың", – дип, яңадан мактыйлар икән. Соңыннан зур бер бутыл самогонның төбенә төшеп, закускасын да мулдан капкалагач, кич утырырга дип, урам көйләрен сиптереп, үз авылларына кайтып китәләр икән.

Өченче юлы да болар чуаш агайның хәлен белеп кайтырга булалар. "Ну, Василий агай, синең кебекләр юк безнең авылда. Кайчан килмә, ачык чырай, такта чәй дигәндәй, шәп каршы аласың", – дип салам кыстырып җибәрәләр. Чуаш агай чоланга чыгып китә дә бу юлы кечкенә генә чәкүшкәне күтәреп кереп өстәлгә утырта. Гаҗәпләнеп калган җегетләргә карап: "Пер – сездән, пер пездән булса яхшы инде ул", – дип куя.

СЕЗНЕ КЕМ АШАТА?..

Элек театр артистлары авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөреп тамаша кылган заманнарда, авыл җирләрендә кунакханәләр булмау сәбәпле, квартирга кертәләр иде. Анда инде сине кемнәр каршы алуы ачылмаган карта кебек. Йә иң якын туганнарын көтеп алгандай, сый табыны әзерләп, киң күңелле хуҗалар каршы ала, йә инде театрга бушлай барыр өчен генә төн кунарга керткән сараннары да очраштыргалый.

Татарстанның халык артисты Тимер Зиннуров та бер иптәше белән квартирага урнашалар. Күпме генә көтеп утырсалар да, хуҗабикә боларга чәй дә куеп эчерми. Күпмедер вакыттан соң теге апай: "Сезне, җегетләр, авыл сәвитеме, колхоз рәисеме ашата?" – дип сорап куя. Көне буе ач йөргән, "чәй эчертерлек тә юмартлыгың булмагач, ник безне фатирга керттең", – дип үпкәләп, рәнҗеп утырган җегетләрнең берсе түзми:

– Без, апа, зур үстек инде хәзер! Безне председатель дә, авыл сәвите дә кашык тотып ашатмый. Үзебез дә калак тотып ашарлык дәрәҗәдә без хәзер, табыныңны гына әзерлә, – дип төрттереп ала.

Хуҗабикә теләр-теләсәм кенә арткы якка чыгып, чәйнеген газга утырта.



Леонид НАСЫРОВ, 1978 ел.



– Кыргыйлар без, ыруыбыздан аерылып калдык!

Герман ОГОРОДНИКОВ, 1969 ел.



• • •

– Мин үземнең тормышымны страховать итәргә телим.

– Машинагыз бармы?

– Юк.

– Мотоциклыгызда йөрисезме?

– Юк.

– Алайса, гафу итегез. Җәяүлеләрне без страховать итмибез – артык куркыныч астына куясыбыз килми!

• • •

Ике таныш сөйләшә:

– Күрәм, машинаң гел подъезд янында тора. Беркая да бармыйсың, ватылдымы әллә?

– Юк. Беләсеңме, мин аны бик уңайлы җиргә куйдым, утырып китсәм, куркам – кем дә булса урынны алыр дип.

• • •

– Мин болай итәм, – дип сүзен башлады бер ханым, – яшемне беркайчан да яшермим. Минемчә, утыз яшь – бик әйбәт!

– Әлбәттә, – ди сердәше. – Бигрәк тә илледән соң...

• • •

Табибка авыру зарлана:

– Минем... менә... ни дип әйтим, ничек атала әле ул, оныткан чагында?

– Бурычлар!..

• • •

Банкка шалтыратталар:

– Психоневрологик диспансер пациентларына кредит бирәсезме?

– Бирәбез, акылыгыз җитмәстәй процентка.

• • •

Олигарх фэн-шуй белгеченә зарлана:

– Минем барысы да дөрес кебек: өем – көнбатышта, алтын приискам – көнчыгышта, көньякта ял итәм, ә бәхетем юк!

– Бу, беләсезме, ни өчен? Сезгә күптәннән төньякка барырга вакыт.

• • •

Мәктәп укытучысы коллегасына әйтә:


– Юк, бөтенләй эшләп булмый башлады. Укытучы директордан курка. Директор – инспектордан. Инспектор – министерстводагы тикшерүчеләрдән. Министр – ата-аналардан. Ата-аналар балаларыннан курка. Балалар гына беркемнән дә курыкмый.

• • •

– Доктор, сезгә ничек итеп рәхмәтемне белдерим икән?

– Кешелек дөньясы акча дигән нәрсәне уйлап чыгару белән, бу – проблема булудан туктады.

Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО





ҖИМЕРЕК МИРАС

Хөрмәтле редакция! Цивилизациянең төп мәгънәсе – төзек канализация. Әгәр бу тәгълимат дөрес икән, ул чагында без ярты елдан артык вәхши хәлгә килгән яшәештә. Мондый сәбәпкә безне бистәбездәге канализация системасы китерде. Аны 1975 елда ук төзегәннәр һәм һәрчак рәтләп, карап торганнар. Күптән түгел бу эшләрне башкаручы әлеге бурычыннан ваз кичкән, ә яңа җаваплылык алганы ватылып, тишелеп, җимерелеп беткән мирас белән нишләргә белми. Шул арада Минэкология белгечләре әйләнә-тирә җиренең пычрануын һәм бик зур зыян күргәнен ачыкладылар. Ә менә кешеләргә күпме зарар килүен чутлаучы берәү дә күренми. Куркыныч парлану һәм исләнүдән байтак халык иза чигә.

Әлегә хакимият һәм элеккеге канализация өчен җавап бирүче әфәнделәр бәхәстән арына алмыйлар – кем штраф түләячәк, яңа хезмәт күрсәтәчәге санап чыгарган: бу системаны рәткә кертү өчен 70 млн. сум кирәк икән, ә андый акча районда юк һәм булуы да бик икеле.

ОСИНОВО бистәсендә яшәүчеләр

ЯШЕЛ ҮЗӘН районы

АҢЛАШЫЛА...


Кадерле "Чаян"! Якын күршең ерак туганыңнан яхшырак, дигән халык мәкале. Әгәр шулай килеп чыкса, билгеле. Мисалга, Ульянов-Ленин урамындагы 23 нче йортта яшәүчеләрне алыйк – күршеләре хостелдагылар булып чыкты. Алар каяндыр килгән "алыштыргысыз һөнәр ияләре". Кайчандыр тыныч яшәгән әлеге урын, кисәк кенә куркыныч булып саналган җиргә әйләнде. Көн-төн тирә-юньдә акырыш-бакырыш, сугыш, кычкырыш... Исерек башлар үтеп-китеп йөрүчеләргә бәйләнәләр, бигрәк тә хатын-кызларга. Кешеләр балаларын урамга чыгарырга куркалар.

Инде, аптырагач, шул тирәдә яшәүчеләр байтак даирәләргә мөрәҗәгать итеп карадылар, килеп тикшереп китүчеләр иңнәрен генә селкетеп куялар – документларына бәйләнерлек түгел – тәртиптә, һәм киләсе шикаять килгәнче югалалар. Аңлашыла: аларның бит андый күршеләре юк.

Т. ҺАДИРОВ

КАЗАН





Валентин ДУБИНИН



Газинур Морат 1959 елның 18 августында Татарстанның Кукмара районы Зур Сәрдек авылында туган. 1976 елда туган авылындагы урта мәктәпне тәмамлагач, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып югары белем ала. 1981 елдан бирле ул журналистлык хезмәтендә: «Татарстан яшьләре» газетасы, балалар журналы «Ялкын» редакцияләрендә, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы иҗат берләшмәсе җитәкчесе, аннан соң Идел» журналы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире һәм 1993–1995 елларда «Татар иле» газетасының баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1995 елдан ул – «Мәдәни җомга» атналык газетасының баш мөхәррир урынбасары хезмәтендә.

Газинур Морат – узган гасырның сиксәненче елларында шигърият мәйданына килгән талантлы яшь буынның бер вәкиле. Студент елларында шигырьләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре республика көндәлек матбугатында бик еш басыла, соңга таба абруйлы «Казан утлары» журналы битләрендә дә шигырь цикллары белән катнаша, ә 1985 елда Татарстан китап нәшриятында «Җир хәтере» исемле мөстәкыйль шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Шул китабы һәм тагын өч елдан соң басылган «Мин дөньяны тыңлыйм» исемле икенче җыентыгы нигезендә ул 1988 елда СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алына. 2000 елда шагыйрь «Түбә» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләгенә лаек булды.

Газинур Морат заманның, татар дөньясының актуаль иҗтимагый мәсьәләләренә, әдәбият-сәнгать проблемаларына багышланган тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләре белән көндәлек матбугатта даими катнаша килә. Бу төр мәкаләләренең бер өлеше аның «Җәяүле кошлар» (2002) исемле китабында урын алган. 2001 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

1994 елдан – ул Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, бер үк вакытта 1999 елдан – Берлек каршындагы Кабул итү коллегиясе әгъзасы.

2007 елда «Төнге әверелеш» китабы өчен ТР Муса Җәлил премиясе белән бүләкләнә.

2016 елда «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен ТР Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм купьеллык иҗади эшчәнлеге өчен 2022 елда Татарстанның халык шагыйре исеме бирелә.

ГӘПТӘШЛӘР

Кичке якта,
фани борчулардан арына төшкәч,
подъезд ишеге төбендә,
агач эскәмиягә утырып,
картлар гәпләшә көн дә.

Кайсы оныгын иярткән,
кайсы – этен,
кайсы тәмәке төрә...

Картлар гәпләшә.

Игеннәр уңды микән?
– Безнең Өчиледә быел
Сабантуй булды микән?
– Көтү дә кайткандыр инде...
– И кордаш, сагышланма.
Печәнгә төшкәндер халык
безнең Салагышта да.

Картлар гәпләшә.

Кичке якта,
подъезд ишеге төбендә,
агач эскәмиягә утырып,
картлар гәпләшә көн дә...

ХАЛЫК ХӘСТӘРЕ

Йоласы шундый:
кышка – печәнсез,
җәйгә әйрәнсез
керми ул халык.

Шундый гадәте:
энәдән алып дастанынача
барлый ул халык.

...Киләчәгенә
телсез-лөгатьсез
бармый ул халык.

ЗӘВЫК

Берәүнең дә кулы җитмәс
Йолдызлар ошый миңа.

Берәүне дә гашыйк итмәс
Буй кызлар ошый миңа.

Һичберәү дә хаталанмас
Хаталар ошый миңа.

Һичкемгә дә охшамаган
Кешеләр ошый миңа.

МИН РИЗА

Һәр гашыйк кавыша алса –
шыксыз төн булырга да;
Һәр кеше көләч яшәсә –
бәхетсез булырга да;
Ил-халыклар туганлашса –
...сәясәт булырга да
мин риза.

ЯРАТЫРГА ТЕЛИМ

(Тәкълид)

Бу дөньяда, бу гөнаһлы Җирдә,
Йә, әйтегез, кем мин?
Әйдә, мине яратмасын беркем –
Яратырга телим.

Кочагыңны аччы, и Сылукай,
Бер юаныйм, эрим.
Син дә әллә яратмыйсың?! –
Ә мин
Яратырга телим.

Синең өчен, бәлки, чыклы иртә,
Бәлки, шыксыз төн мин.
Күкләреңдә тик йолдызлар янсын –
Яратырга телим.

Бу дөньяда, бу гөнаһлы җирдә
Ник яшәлгән – белмим.
Яратырга телим.

ҖАН СУРӘТЕ

Күбәләккә генә әверелә калса
Фани дөнья кичкән һәр бәндәнең җаны,
Нинди мәгънәсез булыр иде хәят!
Нинди мәгънәсез булыр иде дөнья!

Ә Табигать, шөкер, гадел хөкем итә,
Шөкер,Табигатьнең кануннары башка:
Кемнең җаны әверелә гөл-чәчәккә,
Кемнең җаны әверелә ташка.
Кемнең җаны әверелә утка, суга,
Кемнең җаны әверелә үрмәкүчкә,
Кемнең җаны әверелә кыя-тауга,
Очар кошка, йомранга йә кәлтәгә...

Мәгънәлерәк булсын дип җирдә яшәвем,
Мәгънәлерәк булсын дип җирдә үлемем,
Җан сурәте –
Илаһ Табигатькә
Сәҗдә кылам бүген.



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Өчпочмак

Өчпочмак яратмаган кеше бар микән ул? Минем дустым ерак илдә кияүгә чыгып яшәсә дә, өчпочмакны бик ярата. Әнисенә кунакка кайткан саен сыйлана. Быел кайтканда улы аңа:

– Әнием, туган ягыңда өчпочмак пешерергә өйрән әле, мин дә яратам бит аны, – дигән.

Белмим инде, әллә ялкаулыктан, әллә тагын нәрсәдән, дустым бәлешләр пешерми.

Көннәрнең берендә бу миңа шалтырата:

– Әнием шундый тәмле өчпочмаклар пешерде. Улыма да ватсаптан фото җибәрдем. Үпкәләде. Син анда сыйланасың, ә мин монда авыз суларын йотып утырам, – ди.

Берничә сәгатьтән тагын тавышы телефонда:

– Болай дигән: "Әни, безнең чүпрә кайда, он бармы?" дип. Чүпрә юк, онның кайда икәнен аңлаттым. Күпмедер вакыттан бу миңа ватсаптан видео җибәргән. Чүпрәсез өчпочмак пешергән. Дөрес, нинди ит кирәк булуын белмичә, дуңгыз ите салган. Ләкин пешергән бит! "Син генә анда өчпочмаклар белән сыйланып утырма әле, мин дә сыйланам", – дип әйткән.

Дустым миңа фотоларын күрсәтте. Әйе, өчпочмаклары бигүк төзек булмаса да, ярыйсы чыккан. Беренче пешерүе бит малайның! Әтисен дә сыйлаган. Рәхәтләнеп ашаганнар.

Хәзер әнисенә әйтеп куйган: "Әни, үзем пешерәчәкмен моннан соң бәлешләр, синнән көтеп тормаячакмын!" – дигән. Озакламый дустым тагын бер фото җибәргән, малае ипи пешерергә остарган икән.

Менә бит, теләгең булса, кайсы илдә яшәвеңә карамастан, барысын да булдырасың! Эш бит теләктә!

Хәмид ВӘЛИДИ

БЕЛЕП БЕТЕРМИЛӘР ШУЛ...

(90 яшьлек бабай шулай диде)

– Он(ы)тыла кызлар янында
Картлык та, бабайлык та.
Искитми, мөһер сугылмый,
Дөньяви бар байлыкта.

Бер мизгелдә әсир итә
Очкынлы карашлары.
Җегетлегеңне җуймыйча,
Тору кыен аңа каршы.

Җир йөзендәге җәннәттә,
Гүя, син алар белән.
Күз алдына килеп баса
Яшьлектә уйнап-көлгән.

"Аулак өйдә", "Түгәрәк"тә
Кочышып биегән чак.
Дәрмән сүрелсә дә, Дәрт бар,
Суынмаган бит кочак!

Исертә эчми торып та
Кызлардан килгән хуш ис.
Көлсәләр – сибелә көмеш,
Аң югалту мөмкин ич.

Никадәр шаярсалар да,
Алсалар да култыклап.
Кул изәп китеп баралар,
Күңелемне кытыклап.

Белеп бетерми шул кызлар,
Күңел картаймаганны.
Җир – судан, ә ир-җегетләр
Яр сөеп туймаганны.

Рәфкать ИБРАҺИМ

МИЛЛӘТТӘШ ТҮРӘГӘ СҮЗЕМ БАР

Милләттәш түрәгә әйтәм,
Бел син, – дип милләт хәлен,
Беләсеңме аның телен
Һәм гореф-гадәтләрен?

Халкымның теле бетә, – дип
Борчыла беләсеңме?
Милләтең телсез калганга
Әллә сөенәсеңме?

Милләтпәрвәр булганнарны
Нигә читләштерәсең?
Аңа җәза бирүләрне
Гаделлек дип күрәсең.

Милләтеңә булышуны
Кирәк дип санамыйсың,
Мөмкинчелек булганда да,
Уйлап та карамыйсың.

Аңлыйбыз синең хәлеңне,
Синең дә хокук чикле,
Артыгырак кырысланып
Уздырмыйк әле чикне.

Милләтеңә хезмәт итсәң,
Һичкайчан онытылмас,
Башкарган изгелекләрең
Искә алынмый калмас!



Александр ШУЛЬПИНОВ



ЧАЯН
САТИРА һәм
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 9 (1946) сентябрь 2024
Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы,
Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан,
Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.09.2024 ел.
Тираж – 1989 Заказ А-1904
Редакциянең адресы: 420066,
Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
16+
Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!

Зөфәр . . . / Мәсгуть . . . | Фасил . . . / . . . Туишева | Ваһапов | Россиядәге республика | Себердәге елга | Бодай . . .
Иранның акча берәмлеге | "Бик сагындым . . . буйларын"
". . . кирәк" | ". . . — Сары сагыш" / Баланың баласы | Күч, егәр
Иосип Броз . . . | Ым
"Карлыгачлар . . . ясый" / Шамил . . . | "Бу . . ., бу үзәннәрдә" | Нота | Чүп үләне | . . .-су / Егет булса, шук булсын, ике күзе . . . булсын
Урман җәнлеге | Уйсу урын / Әчемлек | "Җидегән чишмәләрдә җиде . . ."
Көлтә киптерү җайланмасы / Урман кошы | Кечкенә тартма | ". . . буйлап" / ". . .ын алтын икән"
"Сызылып киткән кара . . ." | . . . йөзе | "Сутый" / ". . .чы кыз"
". . . кебек тәгәрәп..." / "әрәмәдә — . . ." | "(-1). . . гөл" / Чуер. . . (-1) | Туган ил
Урал елгасы искечә / Чатыр . . .
Һөҗүм авазы
". . . хөзер аралар" | Ир — баш, . . . — муен


НУРИ . . .





6, 3, 13, 5, 2, 10, 7, 4, 9, 12, 1, 8, 11

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Нинди институтка имтихансыз кабул итәләр?

2. Кем ул алкоголик?

3. Асфальт – ни ул?

4. Туктаусыз туклануның иң яхшы чишмәсе?

5. Мәскәүдә вакытлыча фатирга кереп тору күпмегә төшә?

6. Нәрсә ул җитди мөнәсәбәт?

7. Әгәр инде сезне 50 дән соң тормыш шатландырмый башласа нишләргә?

ҖАВАПЛАР

1. Склифосовский институтына. 2. Бүген эчеп булганны, иртәгә калдырмаучы кеше. 3. Җир эшләре башланганчы ук юлларны һәм тротуарларны түши торган материал. 4. Әби. 5. Фотоаппаратка булса, кыйбат түгел. 6. Егет кеше кыз фатирыннан чүп чиләге белән чыга башласа. 7. Тагын 50 не салыгыз.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 8 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«МИНЕМ ТАНЫШ ӨЯНКЕЛӘР»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас),
Х. ӘХМӘТОВ (Кама Тамагы).

Җиңүчебез – Кама Тамагыннан **Халит ӘХМӘТОВ!**



Иран карикатурачылары бездә кунакта




Күптән түгел Татарстанның Милли китапханәсендә китап укуның хәзерге кешенең тормышында тоткан урынына багышланган Иран карикатурачыларының күргәзмәсе ачылган иде. Күңелле рәсем осталарының эшләре алга киткән бүгенге Иранның, үз фикереңне ачык рәвештә җәмгыятькә җиткерергә мөмкин булган демократик дәүләт икәнен дәлилләде.




Саман ТОРАБИ



Алиреза ПАКДЕЛЬ



Аболгасем ТАХАНИАН



Аболгфазл БАХРАМИ

